**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2015 ел, 1 июнь

№ 397

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 313 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә дәүләт идарәсе мәсьәләләре» 2014 ел, 28 ноябрь, ПУ-1091 нче Указын үтәү өчен һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының эшчәнлеген камилләштерү максатында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 313 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 26 сентябрь, 464 нче; 2005 ел, 1 ноябрь, 517 нче; 2005 ел, 29 декабрь, 661 нче; 2006 ел, 1 март, 87 нче; 2006 ел, 21 апрель, 198 нче; 2006 ел, 9 июнь, 293 нче; 2007 ел, 18 май, 196 нчы; 2007 ел, 25 май, 199 нчы; 2008 ел, 28 гыйнвар, 41 нче; 2008 ел, 15 июль, 509 нчы, 2009 ел, 5 июнь, 360 нчы; 2009 ел, 17 август, 551 нче; 2010 ел, 8 июнь, 440 нчы; 2010 ел, 14 октябрь, 808 нче; 2010 ел, 2 декабрь, 976 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 7 октябрь, 838 нче; 2011 ел, 15 ноябрь, 935 нче; 2012 ел, 18 гыйнвар, 25 нче; 2012 ел, 22 август, 726 нчы; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2013 ел, 18 февраль, 110 нчы; 2013 ел, 7 март, 152 нче; 2013 ел, 27 апрель, 286 нчы; 2013 ел, 10 август, 558 нче; 2014 ел, 11 март, 153 нче; 2014 ел, 21 апрель, 261 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктның икенче абзацында «158» санын – «163» санына, «798,378» санын «820,198» санына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы турында нигезләмәдә:

3.1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле ундүртенче абзац өстәргә:

«калдыклар белән эш итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру белән идарә итү (01.06.09 <*>);»;

ундүртенче – егерменче абзацларны унбишенче – егерме беренче абзацлар дип санарга;

3.2 нче пунктта:

кырык бишенче абзацта «вазыйфасын гамәлгә ашырганда» сүзләреннән соң, текстка «республика» сүзен өстәргә, «, капиталь ремонтлауның» сүзләрен төшереп калдырырга;

кырык җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы табигый байлыклардан файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә идарә итү вазыйфасын гамәлгә ашырганда (01.06<*>).»;

кырык сигезенче һәм кырык тугызынчы абзацларны төшереп калдырырга;

3.3 нче пунктта:

3.3.1 нче пунктчада:

тугызынчы абзацтагы «федераль һәм республика максатчан программаларының» сүзләрен «федераль максатчан программаларының һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларының» сүзләренә алмаштырырга;

унберенче абзацтагы «республика һәм ведомство максатчан программаларының» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт һәм ведомство программаларының» сүзләренә алмаштырырга;

егерме җиденче абзацтагы «федераль, республика максатчан һәм ведомство программаларының» сүзләрен «федераль максатчан программаларның, Татарстан Республикасы дәүләт һәм ведомство программаларының» сүзләренә алмаштырырга;

егерме тугызынчы абзацны төшереп калдырырга;

3.3.3 нче пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«эш төрләре буенча бер үлчәү берәмлегенә социаль-мәдәни өлкә объектларын капиталь ремонтлауга иң күп чыгымнар нормативларын раслый;

милек формасына бәйсез рәвештә җир кишәрлекләрендә, шулай ук Татарстан Республикасы милкендә яисә муниципаль милектә булган биналарда яки башка күчемсез мөлкәттә реклама корылмалары урнаштыруның Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан раслана торган схемаларын башлангыч килештерүне, һәм аларга кертелә торган үзгәрешләрне гамәлгә ашыра;

«Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» Федераль законның $16^6$ статьясын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2012 ел, 28 декабрь, ТРЗ-95 нче Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 2 өлеш белән күздә тотылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасында шәһәр төзүне проектлау нормативларының реестрын алып бара.»;

3.3.4 нче пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«күпфатирлы йортларның техник торышына мониторинглау үткәрү тәртибен билгели;

урын милекчеләре күпфатирлы йортларда уртак мөлкәткә капиталь ремонтлау үткәрүне тәэмин итүгә юнәлтелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсуслаштырылган коммерциячел булмаган оешманың (алга таба – төбәк операторы) счетында, счетларында капиталь ремонтлау фондларын формалаштырган күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонтлауны үз вакытында үткәрүне тәэмин итү максатында, төбәк операторы белән хезмәттәшлек итә;

исеменә махсус счет ачылган затның һәм төбәк операторының законнарга ярашлы рәвештә тапшырылырга тиешле белешмәләрне тапшыру тәртибен билгели;

төбәк операторы, шул исәптән Россия Федерациясенең Торак кодексы белән күздә тотылган очракларда җирле үзидарә органнары, муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан, күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) эшләр башкару өчен, подрядчы оешмаларны җәлеп итү тәртибен билгели;

«Генерацияләү компаниясе» ачык акционерлар җәмгыяте, «ТГК-16» ачык акционерлар җәмгыяте, җаваплылыгы чикләнгән «Түбән Кама ТЭЦ» җәмгыяте, «Казан, Түбән Кама, Чаллы, Зәй шәһәрләрендә һәм шәһәр тибындагы Урыссу поселогы «ТГК Урыссу ГРЭС» ябык акционерлык җәмгыятеннән тыш, җирлекләрне һәм шәһәр округларын җылылык белән тәэмин итү чыганакларыннан җылылык белән тәэмин итү системаларының ышанычлылыгын күтәрү буенча чаралар системасын билгели;

пунктка түбәндәге эчтәлекле 3.3.5 нче пунктча өстәргә:

«3.3.5. Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә:

Татарстан Республикасы территориясендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша;

калдыклар белән эш итү өлкәсендә федераль программаларны һәм төбәк программаларын эшләүдә һәм тормышка ашыруда билгеләнгән тәртиптә катнаша;

республикада калдыклар белән идарә итү комплекслы системасын булдыруда, калдыкларны җыю һәм эшкәртү системасын булдыруда катнаша;

калдыклар белән эш итү вакытында барлыкка килгән табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм юк итү буенча планнар эшләүдә һәм чаралар үткәрүдә катнаша;

Россия Федерациясе өчен уртак калдыклар кадастры дәүләт системасын оештыруда һәм алып баруда катнаша, шул исәптән җирле үзидарә органнары, шулай ук калдыклар белән эш итү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыручы юридик затлар тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматларны үз эченә алган төбәк калдыклар кадастрларын алып баруны оештыра, төбәк калдыклар кадастрларын, калдыкларны урнаштыру объектларын, калдыкларны эшкәртү һәм утильләштерүнең технология регламентларын алып бару тәртибен билгели;

халыкны җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендәге мәгълүмат белән тәэмин итүне оештыруда катнаша.»;

4.5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5. Министрлык Татарстан Республикасының ведомстволары карамагындагы дәүләт унитар предприятеләре җитәкчеләрен вазыйфага билгеләүне

һәм вазыйфаларыннан азат итүне, алар белән хезмәт шартнамәләренең гамәлдә булу вакытын билгеләүне килештерүне гамәлгә ашыра.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 313 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 ел, 25 май, 199 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 313 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 ел, 28 гыйнвар, 41 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 313 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 ел, 18 гыйнвар, 25 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 313 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 11 март, 153 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков